**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 июль № 488

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 февраль, 126 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 февраль, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 июль, 556 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.2 нче пунктта «(алга таба – гариза бирүче)» сүзләреннән соң «, шулай ук вәкаләтле орган белән төзелгән контрактлар (шартнамәләр) шартлары нигезендә хуҗасыз хайваннарны тоту буенча план чаралары нигезендә» сүзләрен өстәргә;

2.4 нче пункта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хуҗасыз хайваннарны тоту буенча план чаралары нигезендә хуҗасыз хайваннарны тоту буенча эшләр башкаруга заказ-наряд вәкаләтле орган раслый торган Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы, шәһәр округы территориясендә план буенча хуҗасыз хайваннарны тотуны үткәрү графигы нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан рәсмиләштерелә.

Махсуслаштырылган оешма хуҗасыз хайваннарны тоту буенча план чараларын үткәргәнгә кадәр өч көн алдан халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша хуҗасыз хайваннарны тоту урыннары һәм вакытлары турында хәбәр итәргә тиеш.»

түбәндәге эчтәлекле $2.5^{1}$ – $2.5^{2}$ нче пунктлар өстәргә:

«$2.5^{1}$. Гариза бирүченең хуҗасыз хайваннарны тоту турында мөрәҗәгате вәкаләтле органга язмача яки телдән, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталындагы интернет аша кабул итү, «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы аша электрон документ рәвешендә җибәрелә.

$2.5^{2}$. Махсуслаштырылган оешмалар хуҗасыз хайваннарны тотканда торак массивларда, күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрендә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар территорияләрендә хуҗасыз хайваннар булуын җайга салу мәсьәләләренә аеруча игътибар бирә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков